| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«17» гыйнвар 2025 ел № 37

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 25 июнендәге 590 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 11 июнендәге 540 номерлы карары белән расланган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы турында нигезләмәнең 26 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәткә һәм оборонага әзер «Татарстан Республикасы территориясендә Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын (ГТО) гамәлгә ашыру турында» 2014 елның 04 сентябрендәге 1763-р карарына нигезләнеп, җитештерү зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Сынаулар (тестлар), нормативлар, физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм күнекмәләр дәрәҗәсен бәяләү буенча тест үткәрү үзәген төзү турында» 2015 елның 25 июнендәге 590 номерлы карарына (2016 елның 05 августындагы 740 номерлы, 2019 елның 19 декабрендәге 1097 номерлы, 2024 елның 25 мартындагы 331 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– 1 һәм 2 пунктта «Г.С. Хөсәенов исемендәге балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» МБГБУ сүзләрен «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Атказанган спорт мастеры Галимҗан Салих улы Хөсәенов исемендәге спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга.

– 3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Атказанган спорт мастеры Галимҗан Салих улы Хөсәенов исемендәге спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең тренер-укытучысын Киричок Дария Михайловнаны тестлаштыру үзәгенең баш судьясы итеп билгеләргә..».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К.Габдуллин